| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№_133**

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 25 декабрендәге 829 номерлы карары белән расланган «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» муниципаль программасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
10.02.2020 елның 133 номерлы карарына
кушымта

**«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында»**
**Муниципаль программа паспорты**
**(алга таба – Муниципаль программа)**

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» |
| Программаның җаваплы башкаручысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максаты: | Кукмара муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм урам-юл челтәрләрен саклап калу һәм үстерү. |
| Программаның бурычлары | 1. Район торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының һәм урам-юл челтәрләренең эксплуатация һәм ремонт чараларын үтәү юлы белән сакланышын тәэмин итү.<br>2. Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, урам-юл челтәрләрен һәм алардагы ясалма корылмаларны юлларны һәм алардагы корылмаларны карап тоту юлы белән юллар категориясенә туры килә торган дәрәҗәдә тоту.<br>3. Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының норматив таләпләренә туры килә торган озынлыгын автомобиль юлларын ремонтлау һәм капиталь ремонтлау хисабына саклау.<br>4. Норматив таләпләргә туры килә торган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары озынлыгын арттыру. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2018 – 2020 еллар. |
| Программаның төп чаралары исемлеге | 1. Кукмара муниципаль районы чикләрендә урнашкан җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм урам-юл челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау.<br>2. Кукмара муниципаль районы чикләрендә урнашкан җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм урам-юл челтәрләрен реконструкцияләү |

| | |
|---|---|
| | һәм капиталь ремонтлау. |
| Программаны ресурслар белән тәэмин итү | Программаны финанслау җирле бюджет акчалары хисабына, Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә торган бензинга, дизель ягулыгына, мотор майларына акцизлардан кергән керемнәр хисабына карала Финанслауның гомуми күләме 77 360,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2018 ел – 25 669,6 мең сум<br>2019 елда – 26 490,9 мең сум<br>2020 ел – 25 200,0 мең сум<br>Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Кукмара муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы ремонтланган автомобиль юллары һәм урам-юл челтәрләренең озынлыгы 10,5 км тәшкил итә. |

## РАЗДЕЛ 1. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ ӨЛКӘСЕНЕҢ АГЫМДАГЫ ТОРЫШЫ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

Хәзерге вакытта районның авыл эчендәге автомобиль юлларының озынлыгы 603,9 км тәшкил итә.

Автомобиль юллары әйләнә-тирә мохиткә, кешенең хуҗалык эшчәнлегенә һәм транспорт чараларының даими йогынтысына дучар ителә, шуның нәтиҗәсендә юлларның техник-эксплуатацион торышы үзгәрә. Аларны норматив таләпләргә туры китерү өчен төрле юл эшләрен башкару зарур:

автомобиль юлын карап тоту – автомобиль юлының тиешле техник торышын саклау, аның техник торышын бәяләү, шулай ук юл хәрәкәте иминлеген оештыру һәм тәэмин итү буенча эшләр комплексы;

автомобиль юлын ремонтлау – автомобиль юлының транспорт-эксплуатация характеристикаларын торгызу буенча үтәү барышында автомобиль юлының конструктив һәм башка ышанычлылык характеристикаларына һәм куркынычсызлыгына кагылмый торган эшләр комплексы;

автомобиль юлын капиталь ремонтлау – автомобиль юлының, юл корылмаларының һәм (яки) аларның өлешләренең конструктив элементларын алмаштыру һәм (яки) торгызу буенча эшләр комплексы, аларны үтәү автомобиль юлының билгеләнгән рөхсәт ителгән зурлыклары һәм классның техник характеристикалары һәм категориясе чикләрендә башкарыла, һәм аларны үтәгәндә автомобиль юлының конструктив һәм башка ышанычлылык характеристикаларына һәм куркынычсызлыгына кагыла, автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның чикләре үзгәрми;

автомобиль юлын реконструкцияләү – автомобиль юлының, аның участокларының параметрларын үзгәртү гамәлгә ашырыла торган, автомобиль

юлының классын һәм (яки) категориясен үзгәртүгә яисә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның чикләрен үзгәртүгә китерә торган эшләр комплексы.

Юллар челтәренең торышы юлларны карап тоту, ремонтлау, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү буенча эшләрнең вакытында, тулы һәм сыйфатлы башкарылуы белән билгеләнә һәм финанслау күләменә һәм аларның чикләнгән күләмнәре шартларында финанс ресурсларын бүлү стратегиясенә турыдан-туры бәйле.

Хәрәкәт интенсивлыгының даими үсүе, хәрәкәт составын транспорт чараларының йөк күтәрүчәнлеген арттыру ягына үзгәртү шартларында юл тармагын финанслап бетермәү ремонтара сроклар үтәлмәүгә, ремонтланмаган участоклар саны тупланууга, йөкләнеше нормативтан югарырак булган һәм транспорт-эксплуатация торышы канәгатьләнмәслек булган реконструкция үткәрергә кирәк булган участоклар саны артуга китерә.

Күрсәткечләрне яхшырту өчен, автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү өчен бүлеп бирелә торган акчаларны арттыру зарур.

Автомобиль юлларында хәрәкәт интенсивлыгы үсеше темпларының автомобиль юлларының озынлыгы һәм үткәрүчәнлек сәләте үсү белән чагыштырганда артуы район автомобиль юлларында авариялелек дәрәҗәсе артуга китерә.

Автомобильләр йөрүнең фаразланган күләмнәрен тәэмин итү өчен, юлларны транспорт-эксплуатация торышы буенча норматив таләпләргә туры китерү таләп ителә.

Районның җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының торышы канәгатьләнерлек хәлдә түгел, аларны ремонтлау таләп ителә.

Транспорт-эксплуатация күрсәткечләре норматив таләпләргә туры килми торган автомобиль юлларында йөк ташуның үзкыйммәте арта, ә хәрәкәт куркынычсызлыгы начарлана.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, финанс чаралары чикләнгән шартларда, автомобиль юлларының проблемалы участоклары санын мөмкин кадәр киметү максатыннан, аларны оптималь куллану бурычы тора.

Районда гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын үстерүдә программа-максатчан методны куллану акчаларны финанс ресурслары чикле булган шартларда юл тармагының кичектергесез проблемаларын хәл итүгә системалы рәвештә җибәрергә һәм барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның тырышлыкларын координацияләргә мөмкинлек бирәчәк.

Программа чаралары комплексын тормышка ашыру түбәндәге хәвеф-хәтәрләр белән бәйле:

икътисад үсеше темпларының һәм инвестицион активлык дәрәҗәсенең кимүенә, бюджет дефицитының барлыкка килүенә, юл тармагын финанслау күләмнәренең кимүенә китерәчәк илдәге социаль-икътисади вәзгыятьнең начараю куркынычы;

төзелеш материалларына, машиналарга, махсуслаштырылган җиһазларга бәяләрнең тизләтелгән артуы юл эшләре бәясе артуга, автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонт, ремонт һәм карап тоту күләмнәренең кимүенә китерергә мөмкин булган фаразланган күрсәткеч белән чагыштырганда инфляциянең факттагы дәрәҗәсен арттыру куркынычы;

программаны тормышка ашыру чорында район автомобиль юлларында ремонт эшләрен башкаруда җыелган артта калуны шактый киметергә һәм

программада планлаштырылган күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирми торган акча чыгымнары нормативлары нигезендә автомобиль юлларын карап тоту, ремонт һәм капиталь ремонт эшләрен финанслауга күчүне тоткарлау куркынычы.

## Кисәк 2. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ ҺӘМ БУРЫЧЫ, ТОРМЫШКА АШЫРУ ВАКЫТЫ

Муниципаль программаның максаты – юл хуҗалыгының өзлексез һәм куркынычсыз эшләвен тәэмин итү.

Муниципаль программа максатына ирешү Кукмара муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын саклау һәм үстерү бурычын хәл итү юлы белән тәэмин ителә.

Муниципаль программа бурычларын хәл итү түбәндәге максатчан күрсәткечләргә ирешү юлы белән тәэмин ителәчәк:

район торак пунктлары чикләрендә урнашкан, транспорт-эксплуатация күрсәткечләренең норматив таләпләренә җавап бирми торган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары озынлыгы 2% ка кадәр кимиячәк;

Муниципаль программаның максатчан күрсәткечләренә ирешү өчен мөһим факторлар: автомобиль бензинына һәм дизель ягулыгына акцизларның яңа ставкаларын кертү буенча чаралар күрү, республика һәм федераль бюджет акчаларын җәлеп итү хисабына  Кукмара муниципаль районының Юл фонды керемнәрен арттыру.

Муниципаль программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру сроклары муниципаль программаны гамәлгә ашыруның гомуми вакытына туры килә – 3 ел.

## РАЗДЕЛ 3. ПРОГРАММАНЫҢ НИГЕЗЛӘНЕШЕ

Программаның җаваплы башкаручысы – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты. Программа чараларын финанслау күләме:

2018 елга – 25 669,6 мең сум,

2019 елга – 26 490,9 мең сум,

2020 елга – 25 200,0 мең сум

Программа Кукмара муниципаль районының торак пунктлары чикләрендә урнашкан автомобиль юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау буенча чараларны үз эченә ала.

Программа чараларын тормышка ашыру норматив таләпләргә җавап бирә торган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары озынлыгын арттыруга, юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән.

Программа чараларын тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре булып район торак пунктлары чикләрендә урнашкан, транспорт-эксплуатация күрсәткечләренең норматив таләпләренә җавап бирми торган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары озынлыгының өлешенең кимүе, автомобиль юлларында юл-транспорт һәлакәтләре саны кимү тора.